БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИE** **КАРАР**

«18» 01 2023 ел № 29

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 16 августындагы 247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм аларны оешмага җибәрү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 12 нче кушымтаның 19 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«19. Бала, шул исәптән уллыкка алынган (кызлыкка алынган) яки тәрбиягә алган гаиләне яисә Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда патронат гаиләне дә кертеп, гаиләдә опека яки попечительлек астында булган бала (ата-анасы бер булган һәм атасы яисә анасы башка булган абыйсы һәм (яисә) апасы, уллыкка (кызлыкка) алынган абыйсы һәм (яисә) апасы, опекуннары (попечительләре) бу баланың ата-анасы (законлы вәкилләре) булган балалар яисә ата-анасы (законлы вәкилләре) бу баланың опекуннары (попечительләре) булган балалар укыган («Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләрендә каралган очраклардан тыш) муниципаль мәгариф оешмасында мәктәпкәчә белем бирү программасы буенча укуга өстенлекле кабул итү хокукына ия.

2. Түбәндәге административ регламентларга үзгәрешләр кертергә:

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 17 гыйнварындагы 30 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында каникуллар вакытында балаларның ялын оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 17 гыйнварындагы 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының өстәмә гомуми

белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 113 номерлы карары белән расланган җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкаруга проект документларын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 114 номерлы карары белән расланган Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 115 номерлы карары белән расланган бинаны торак бина, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 116 номерлы карары белән расланган юл билгеләрендә индивидуаль проектлауның мәгълүмат билгеләрен урнаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 117 номерлы карары белән расланган җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкаруга йөкләмә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 118 номерлы карары белән расланган җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 119 номерлы карары белән расланган 16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 120 номерлы карары белән расланган җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 121 номерлы карары белән расланган муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарын алмаштыру буенча документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 123 номерлы карары белән расланган җирлек территориясе өстендә авиация эшләре, парашют белән сикерүләр, һава судноларының күрсәтү очышларын, пилотсыз очу аппаратлары очышларын, тагылма аэростатларны күтәрүне башкару өчен рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 124 номерлы карары белән расланган җирлекнең Генераль планыннан яисә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләреннән өземтә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 125 номерлы карары белән расланган ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 126 номерлы карары белән расланган муниципаль милектә булган җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру өчен шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 127 номерлы карары белән расланган муниципаль милектә булган су объектларын судан файдалану шартнамәсе яки су объектын файдалануга бирү турында карар нигезендә файдалануга тапшыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 128 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасы буенча торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләү алуга исәпкә кую һәм социаль түләү алу хокукы турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 18 мартындагы 152 номерлы карары белән расланган муниципаль мөлкәт реестрыннан исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 18 мартындагы 153 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге һәм арендага бирү өчен билгеләнгән күчемсез мөлкәт объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 18 мартындагы 154 номерлы карары белән расланган муниципаль берәмлекнең муниципаль мөлкәтен сатулар үткәрмичә генә түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 18 мартындагы 155 номерлы карары белән расланган муниципаль мөлкәтне арендага, оператив идарә итүгә, түләүсез файдалануга,

хуҗалык алып баруга бирү шартнамәсенә үзгәрешләр кертү турында өстәмә килешү төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 18 мартындагы 156 номерлы карары белән расланган муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 18 мартындагы 157 номерлы карары белән расланган мондый шартнамәне төзү хокукына сату нәтиҗәләре буенча муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану шартнамәсе төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 18 мартындагы 158 номерлы карары белән расланган җир кишәрлегеннән даими (чикләнмәгән вакытка) файдалану хокукын яки җир кишәрлегенә гомерлек мирас итеп алу хокукын туктату турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 18 мартындагы 159 номерлы карары белән расланган җир кишәрлеге сатып алу турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 18 мартындагы 160 номерлы карары белән расланган элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 28 июнендәге 204 номерлы карары белән расланган Гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 26 июлендәге 223 номерлы карары белән расланган муниципаль контроль буенча чаралар үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 6 октябрендәге 314 номерлы карары белән расланган мәгълүмати элмә такталар урнаштыру, элмә такталар урнаштыруның дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 6 октябрендәге 316 номерлы карары белән расланган Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләрне, документларны, материалларны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 6 октябрендәге 317 номерлы карары белән расланган социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны

наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү:

2.1. преамбулда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2. 3.3.2.1 пунктындагы унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Форматлы-логик тикшерү Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең электрон формадагы гарызнамәсенең һәр кырын тутыру процессында Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан гарызнамәнең электрон формада дөрес тутырылмаган электрон кыры ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә турыдан-туры электрон гарызнамә формасында мәгълүмат хәбәре аша ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.».

3. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 6 октябрендәге 319 номерлы карары белән расланган гражданнарны җир кишәрлекләрен милеккә бушлай алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1. преамбулда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.2. 3.3.1.1 пунктындагы унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Форматлы-логик тикшерү Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең электрон формадагы гарызнамәсенең һәр кырын тутыру процессында Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан гарызнамәнең электрон формада дөрес тутырылмаган электрон кыры ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә турыдан-туры электрон гарызнамә формасында мәгълүмат хәбәре аша ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.».

4. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 6 августындагы 235 номерлы карары белән расланган җир

кишәрлекләре бирмичә һәм сервитут, гавами сервитут билгеләмичә дәүләт яки муниципаль милектә булган җирләрдән яки җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1. преамбулда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.2. 2.8.2 пунктының 8 пунктчасында «Җир кишәрлекләреннән файдалануның рөхсәт ителгән төрләре классификаторын раслау турында» 2014 елның 1 сентябрендәге 540 номерлы Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгы боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән файдалануның рөхсәт ителгән төрләре классификаторы» сүзләрен «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең 2022 елның 10 ноябрендәге П/0412 номерлы боерыгы белән расланган җир кишәрлекләреннән файдалануның рөхсәт ителгән төрләре классификаторы» сүзләренә алмаштырырга;

4.3. 2.8.2 пунктындагы 12 пунктчасында «бакчачылыкны» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылыкны алып барулары» сүзләренә алмаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 19 августындагы 261 номерлы карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.1. преамбулда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.2. 1.5 пунктының унынчы абзацына «аларга караганлыкны билгеләүче Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган критерийлар» сүзләрен өстәргә.

6. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 9 августындагы 240 номерлы карары белән расланган реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү, элек бирелгән рөхсәтләрне гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.1. преамбулда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында

һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.2. 2.8.2 пунктының 6 пунктчасында «5.1, 5.6, 5.7 өлешләре белән» сүзләрен «реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йортта бина милекчеләренең гомуми милке файдаланылган очракта, 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 5 өлеше белән, 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 5.6, 5.7 өлешләре белән» сүзләренә алмаштырырга.

7. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 260 номерлы карары белән расланган төзелеш планлаштырылу турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7.1. преамбулда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.2. 2.5.1 пунктының беренче абзацында «шәхси торак төзелеше объектын төзү яисә реконструкцияләү» сүзләрен «шәхси торак төзелеше объектын төзү, реконструкцияләү (индивидуаль торак төзелеше объектларын «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп шәхси торак төзелеше объектларын төзүдән тыш)» сүзләренә алмаштырырга.

8. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 20 августындагы 263 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны социаль ипотека системасында исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8.1. преамбулда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып» сүзләрен төшереп калдырырга;

8.2. 2.6.1 пунктының 12, 17 һәм 18 пунктчаларында «Россия Федерациясе пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга.

9. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 255 номерлы карары белән расланган җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9.1. преамбулда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып» сүзләрен төшереп калдырырга;

9.2. 2.8.3.2 пунктының 13 пунктчасында «бакчачылык» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылыкны алып барулары» сүзләренә алмаштырырга.

10. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 6 октябрендәге 320 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга, түләүсез нигездә файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10.1. преамбулда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып» сүзләрен төшереп калдырырга;

10.2. 3.3.2.1 пунктындагы унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Форматлы-логик тикшерү Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең электрон формадагы гарызнамәсенең һәр кырын тутыру процессында Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан гарызнамәнең электрон формада дөрес тутырылмаган электрон кыры ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә турыдан-туры электрон гарызнамә формасында мәгълүмат хәбәре аша ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

10.3. 2.8.2.1 пунктының 13 пунктчасында «бакчачылыкны» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылыкны алып барулары» сүзләренә алмаштырырга.

11. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 256 номерлы карары белән расланган җир кишәрлеген арендага, милеккә түләүле нигездә сатулар үткәрмичә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11.1. преамбулда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып» сүзләрен төшереп калдырырга;

11.2. 2.8.2.1 пунктының 13 пунктчасында «бакчачылык» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылыкны алып барулары» сүзләренә алмаштырырга.

12. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 6 августындагы 231 номерлы карары белән расланган бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

12.1. преамбулда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып» сүзләрен төшереп калдырырга;

12.2. 2.8.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 8 пунктчаны өстәргә:

«8) су басу, су керү зонасы чикләрендә урнашкан җир кишәрлегендә бакча йорты урнаштыру (бакча йортын торак йорт дип тану турында гариза каралганда)».

13. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 253 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир кишәрлегенә карата сервитут (гавами сервитут) билгеләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

13.1. преамбулда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып» сүзләрен төшереп калдырырга;

13.2. 2.8.2.1 пунктының 6 пунктчасына «линия объектлары булган инженерлык корылмаларына капиталь ремонтлау максатларында, шулай ук мондый инженерлык корылмаларының участокларына (өлешләренә) капиталь ремонт ясау максатларында гавами сервитут билгеләү очрагыннан тыш» сүзләрен өстәргә.

14. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 6 октябрендәге 318 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир кишәрлеген милеккә бушлай бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

14.1. преамбулда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып» сүзләрен төшереп калдырырга;

14.2. 3.3.2.1 пунктындагы унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Форматлы-логик тикшерү Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең электрон формадагы гарызнамәсенең һәр кырын тутыру процессында Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан гарызнамәнең электрон формада дөрес тутырылмаган электрон кыры ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә турыдан-туры электрон гарызнамә формасында мәгълүмат хәбәре аша ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

14.3. 2.8.2 пунктының 13 пунктчасында «бакчачылык» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылыкны алып барулары» сүзләренә алмаштырырга.

15. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

16. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов